
8 ноябрьдә доньякvләм танылган скульптор Степан Дмитриевич Эрьзянын (Нефедовнын) тууына 145 ел тула. Анын талантлы һәм vзенчәлекле ижаты милли генә тvгел, ә донья мәдәниятенен якты сәхифәләреннән берсе булып тора.
Ул 1876 елда Сембер губернасы (хәзер Мордовия Республикасынын Ардатово районы) Алатырь оязе Баево авылында туа. Балачагы һәм яшьлеге Сембер губернасы Алатырь оязенен Баев Выселкасы авылында уздырыла. Шул ук оязнен Алтышево авылындагы чиркәv-приход мәктәбен тәмамлый, ә 1892 елда гаиләсе Алатырьга кvчеп килә.
Булачак скульптор беренче сәнгать кvнекмәләрен Алатырь һәм Казан иконоязма остаханәләрендә ала. Ул Идел буе авыллары һәм шәһәрләре чиркәvләренен рәсемнәре остендә эшли.
1896 елда Степан Нефёдов Михаил Врубель кvргәзмәсенә эләгә. Танылган рәссамнын эшләре аны шундый рухландырган ки, ул рәсем сәнгатен ойрәнергә һәм югары белем алырга карар кыла. Һәм 1901 елда Степан Нефёдов Мәскәv рәсем сәнгате училищесына укырга керә. Анын укытучылары Константин Коровин, Валентин Серов, Леонид Пастернак һәм башка кvренекле рәссамнар була.
1903 елда яшь рәссам Сергей Волухин һәм Павел Трубецкой укыткан скульптура бvлегенә кvчә. Бу вакытта Нефёдов чын фамилия урынына Эрьзя псевдонимы ала. 1906 елда Степан Нефёдов-Эрьзя укуын тәмамлый һәм 1906-1914 елларда Италия белән Франциядә яшәгән, анда «Сагыну» («Тоска»), «Автопортрет» (1908), «Тормә руханиы» («Тюремный священник»), «Жәза алдында хокем ителгәннен сонгы тоне» («Последняя ночь осужденного перед казнью»)  (1909), «Таш гасыр» ( «Каменный век») (1911), «Марта» (1912) һәм башка әсәрләрне ижат иткән. Алар рәссамнын кеше хисләре доньясына тирән vтеп керv һәм аны пластика чаралары белән чагылдыру турында сойли.
«Жәза алдында хокем ителгәннен сонгы тоне» эше Эрьзянын беренче зур унышы була. Мастер аны Мәскәvдә Бутыр тормәсеннән алган тәэсирләре нәтижәсендә булдырган: уку елларында ул хокем ителгән революционерларны фотога тошергән. Скульптура 1909 елда Венециядә узган Халыкара кvргәзмәдә 1 урынны алган. Кvргәзмәгә килvчеләр аз билгеле скульпторны «Рус Родены» һәм «Авыл Микеланджелосы» дип атый башлыйлар. Шулай анын кvргәзмәләре донья буйлап сәяхәт итә башлыйлар. Милан шәһәрендә (Италия, 1909), Париж шәһәрендә (Франция, 1912) «Козге салон» кvргәзмәсендә катнашу ана доньякvләм танылу китерә.
1914 елда Беренче ботендонья сугышы башлана һәм Степан Эрьзя Россиягә кайта. Сугыш вакытында ул Мәскәv хәрби госпиталендә санитар булып эшли, скульптура белән шо-гыльләнергә вакыты калмый диярлек. Бу чордагы ин сирәк эшләрнен берсе- «Монголка» һәм «Софья Федорованын балеринасы портреты». Яраткан мрамордан тыш,

мастер vзе очен яна материаллар - цемент, тимер-бетон, металл белән дә эшли башлый. Шул ук чорда ул агач белән дә мавыга: мона аны мордва осталарынын эшләнмәләре рухландыра.
Эрьзя ижатындагы яна этап 1917 елнын Октябрь революциясеннән сон башлана. Материал һәм эш очен ин яхшы шартлар эзләп, ул ил буйлап йори, Уралда (1918 -1921), Новороссийск (1921 - 1922), Батуми (1922), Бакуда (1923 -1925) яши. Скульптор монументаль әсәрләр ижат итә.  Мәсәлән, «1905 елгы революция корбаннары» әсәре ирек очен һәлак булган корәшчеләргә vзенчәлекле Реквием булып кабул ителә. Әсәрнен кискен чыгышлары белән тигез булмаган ослеге, динамик яктылык эффектлары, экспрессив лепка скульптураны эмоциональ яктан баеталар.
1927-1950 елларда С.Д.Эрьзя Аргентинада яши. Биредә ул  скульптура эшләрендә беренче тапкыр Коньяк Американын токымлы агачы - кебрачо белән альгаррободан файдаланган. Степан Эрьзя кеб-рачо һәм альгарробо белән эшләгәндә, скульптура сәнгатенә агач эшкәртv буенча vзенчәлекле техника - материалнын табигый матурлыгын ачыклаучы гадәти булмаган композицион алымнарны кертә. Скульптура портреты жанрында кvп сандагы әсәрләр башкарыла: «Карл Маркс» (1927), «Бетховен» (1929), «Лев Толстой» (1930), «Александр Невский» (1931), «Сократ», «Микеланджело» (1940), «В.И.Ленин» (1956). Билгеле бер кеше сурәтендә ул анын ин характерлы сыйфатларын кvрсәткән.
Эрьзянын Библия сюжетлары буенча эш-ләгән әсәрләре:  «Ева» (1919), «Иоанн Креститель» (1928), «Моисей» (1932), «Мәсих» (1945) мәхәббәт, игелек һәм явызлыкнын мәнгелек тошенчәләрен гәвдәләндерә. Скульптор ижатынын vзенчәлеге - психологизм, кешелек хисләренен нечкә тосләрен бирә белv. Тагы С.Д.Эрьзяда хатын-кызлар образларынын доньясы торле. Аларда кайгы - «Хатын - кыз портреты» (1934), «Монахиня» (1941), «Чилийка» (1943), демоник матурлык - «Медуза» (1938), «Испанка» (1942), яшьлек учагы - «Француз кызы» (1938), «Парагвай кызы» (1941), «Койсезлек» (1944) бар. Якты хатын-кыз образларынын берсе – «Ана портреты» (1940).
Скульптор ижаты тирән патриотизм хисе белән сугарылган. Бу милли образлар булдыруда да чагылыш тапкан: «Эр-зянка» (1915), «Голова мордовки» (1917), «Крестьянин-мордвин» (1937), «Портрет матери» (1940), «Портрет отца», «Старик-мордвин» (1944), «Мордвин с папиросой» (1948)... Бу эшләр vзләренен абруйлары, зирәклеге һәм йомшак халык юмор хисе белән vрелеп бара. Ватаныбызны сагынып, Эрьзя туган-тумачаларына һәм якыннарына багышлаган; аларны аеруча жылылык һәм жанлылык кертеп яза.
1950 елда Эрьзя, совет житәкчелеге рохсәтен алып, туган ягына әйләнеп кайта һәм 1950-1959 елларда Мәскәvдә яши һәм эшли. 175 тоннадан артык агач, гипс, бронза, мрамордан - 200дән артык скульптура ул vзе белән алып килгән һәм vз иленә, халкына бушлай тапшырган.
Хокvмәт ана Мәскәvдә остаханә бvлеп биргән һәм С.Д.Эрьзя анда эшләгән. 1954 елда vз эшләренен шәхси кvргәзмәсен дә шунда оештыра. Бу елларда «Москвичка» (1953), «Студентка» (1954), «Портрет Шакен Ахметжановой» һ. б. портретлар ижат итә.
1956 елда сынчы (скульптор) Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бvләкләнә.
Степан Дмитриевич Эрьзя 1959 елнын 24 ноябрендә Мәскәvдә вафат була. Аны Саранскида жирлиләр.
Рәссамнын исеме мәнгеләштерелә: 1960 елда Мордовия сынлы сәнгать музеена нигез салынган, Новороссийскидагы сәнгать мәктәбе, Мәскәv, Саранск һәм Ардатовтагы

урамнар скульптор исемен йортәләр. Эрьзянын тормышы һәм ижаты документаль һәм нәфис әдәбиятта чагылыш тапты: (К.Г.Абрамов, В.А.Гадаев, В.Ф.Егоров һ. б. әсәрләрендә), музыкаль сәнгатьтә («Чародей» опереттасы - В.П.Беренков музыкасы, В.И.Есьман һәм К.А.Крикорян либреттолары; фортепиано музыкасында- Г.Г.Вдовин һәм симфоник музыкасында - Н.В.Кошелева, Е.В.Кузина, С.Я.Терханов). Эрьзя образы рәсем сәнгатендә торгызылды (В.Ф.Макаров, Е.А.Ноздрин, И.И.Сидельников, М.С.Шанин картинала-ры, графика буенча А.С.Алешкин, Н.Н.Жу-ков, А.И.Коровин, Н.С.Макушкин, В.А.Поп-ков эшләре,  скульптурада (С.Т.Конёнков, Г.М.Филатов, Н.М.Филатов). Скульпторнын тормышына һәм ижатына багышланган бик кvп альбомнар донья кvрде. Владимир Васильевич Райский һәм Юрий Әхтәм улы Шәйгарданов тарафыннан анын турында документаль фильмнар тошерелде. Эрьзянын тууына 125 ел тулуга компакт-диск (проект житәкчесе - Наталья Ивановна Воронина) чыгарылды. Мордовиядә «Сынлы сәнгать олкәсендә Степан Эрьзя исемендәге премия лауреаты» исеме гамәлгә куелды. Анын истәлегенә мемориаль такталар багышланган: Мәскәvдә, Саранскта һәм Ульяновскида. Сынчынын туган авылында, Баевода С.Д.Эрьзя музей-йорты ачылды. Республикабызда 1996 елдан бирле С.Эрьзя укулары vткәрелә. Мордовия Республикасынын А.С.Пушкин исемендәге Милли китапханәсенен милли һәм туган якны ойрәнv әдәбияты бvлеге С.Д.Эрьзянын юбелеена «Бер китап уку» онлайн-проектын багышлады. Бvлек хез-мәткәрләре Мордовиянен халык язучысы К.Г.Абрамовнын «Степан Дмитриевич Эрьзя» исемле биографик очергын укыйлар. Скульпторнын эшләрен илебезнен торле музейларында кvрергә була. Степан Эрьзя әсәрләренен ин зур кvргәзмәсе - 200 дән артык эш - анын исемен йорткән Мордовия Республикасынын Сынлы сәнгать музеенда.

**Альфия МАЛАНЬЧЕВА**, *Мордовиянен А.С.Пушкин*
*исемендэге МК,*
*милли эдэбият hэм туган якны өйрэнv бvлеге баш китапханэчесе*